# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең Олы Яке авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**22 октябрь 2022 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә тцрында” 2004 елның 28 июлендәге 35 статьясы нигезендә № 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 22 нче октябрендә 14 сәгать 00 минутта һәм 16 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: «Сез 2023 елда Яшел Үзән муниципаль районының Олы Җәке авыл җирлеге торак пункты Олы Яке авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 750 сум күләмендә үзара салым кертергә килешәсезме ?,
искәрмә: мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 нче группа инвалидлар, күп балалы гаиләләр һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:

- зиратны төзекләндерү;
- спорт комплексы төзергә:
- асфальт кисәкчекләре сатып алу;
- җәяүлеләр йөрер өчен күпер салу Үзәк урамга;

**“ ӘЙЕ”** **“КАРШЫ”**

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегендә 413 кеше,
Халык җыенында 235 кеше тавыш бирүдә катнашты, бу 56,9% тәшкил итә.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде:
“ӘЙЕ” позициясе өчен җыенда 223 кеше тавыш бирде;
“КАРШЫ” позициясе өчен җыенда 10 кеше тавыш бирде;
“ТОТКАРЛАНАМ” позициясе өчен 2 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең Олы Яке торак пунктында гражданнар җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.
2. 2023 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең Олы Яке авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган кешедән 750 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.
искәрмә: мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 нче группа инвалидлар, күп балалы гаиләләр.
3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- зиратны төзекләндерү;

- спорт комплексы төзергә:
-  асфальт кисәкчекләре сатып алу;
- җәяүлеләр йөрер өчен күпер салу Үзәк урамга;

4. Әлеге карарны  Олы Яке авылы, Школьная урамы, 1 нче йорт (администрация бинасы), Олы Яке авылы, Школьная урамы, 1а йорт (Олы Җәке күпфункцияле үзәге бинасы), Каратмән авылы, Клуб урамы, 23 нче йорт(Каратмән авыл клубы бинасы), Уразлы авылы, Подгорная урамы 138П (Уразлы авыл клубы бинасы), Зеленодольск муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ____________ Ф. А. Фәйзуллина